ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина,**
**Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина**

# ДИДАКТИК УЕННАР

«Туган тел (татар теле)» һәм «Әдәби уку»
дәресләрендә куллану өчен

КАЗАН
2019

**М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина,**

**Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина**

# ДИДАКТИК УЕННАР

«Туган тел (татар теле)» һәм «Әдәби уку» дәресләрендә куллану өчен

(башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен)

КАЗАН

2019

УДК 811.512 (075.2)

ББК 81=632.3я71

Ш 92

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
дәүләт йөкләмәсе кысаларында эшләнде

**Шакурова М.М.**

Дидактик уеннар: «Туган тел (татар теле)» һәм «Әдәби уку» дәресләрендә куллану өчен. Башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен методик әсбап / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2019. – 60 б.

Методик әсбапта ФДБСка нигезләп эшләнгән «Туган тел (татар теле)» һәм «Әдәби уку» дәресләрендә файдалану өчен дидактик уеннар туплап бирелде. Ул башлангыч сыйныфларда эшләүче укытучыларга тәкъдим ителә.

УДК 811.512(075.2)
ББК 81=632.3я71
Ш 92

© М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина
Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина, 2019

# КЕРЕШ СҮЗ

Уен технологиясенең роле һәм әһәмияте туган телгә һәм әдәби укуга өйрәтү дәресләренең актуальләштерү, уку мәсьәләсен өлешләп чишү этапларында аеруча зур. Уен – танып белүгә кызыксыну уята һәм укучылар эшчәнлеген активлаштыра торган тәрбия чарасы ул. Дидактик уеннар хәтерне яхшырта, укучыларга сөйләм осталыклары һәм күнекмәләрен формалаштырырга ярдәм итә. Гомумән, уен укучыларның акыл эшчәнлеген арттыра, игътибарлылык һәм предметка карата кызыксынучанлыкны үстерә, аларны активлаштыра, командада эшләргә өйрәтә. Һәр укучы үз командасының югары нәтиҗәләргә ирешүен тели, тиз һәм уңышлы рәвештә биремнәрне үти.

ФДБС нигезләнгән туган тел (татар теле) дәресләрендә фонетик, лексик, грамматик материалны үзләштерү белән берлектә укучыларны иҗади эшләргә, мөстәкыйль, креатив итеп уйларга өйрәткәндә, хәрәкәтле, рольле һәм компьютер уеннары яратып кулланыла («Яшерелгән сүзне тап», «Йорт хайваннары һәм кошлары атамаларындагы сузыкларны тап», «Кем тизрәк укый?», «Алма җыю», «Яңа ел чыршысы», «Сабантуйга бәйле рәсемнәрне кара һәм парларын табып яз» һ.б.).

Әйтик, әсәрләрне рольләргә бүлеп, сәхнәләштерү; әзер детальләр ярдәмендә әсәр геройларын “киендерү”, аерым темаларны йомгаклаганда, билгеле бер әсәрне укыгач, кроссвордлар һәм ребуслар чишү яки аларны бергәләп эшләү, сөйләмне һәм хәтерне үстерү өчен башлангыч сүздән логик чылбыр төзү, башлангыч җөмлә нигезендә күмәк хикәя (әкият, шигырь) иҗат итү, һәм башка бик күп төрле уеннар кулланырга була.

Шулай итеп, уен технологиясе укучыларның белемнәрен ныгытуга юнәлтелгән, төрле иҗади ысуллар кулланып эшләнә торган, укучыны мөстәкыйль, үзлектән һәм мәгълүмати җирлектә эшли белергә өйрәтә.

# УЙНАВЫН УЙНА...

Федераль дәүләт башлангыч белем бирү стандарты нигезендә мәктәптә белем бирүнең төп максаты – балаларда гомуми күнекмәләр һәм осталыклар булдыру белән беррәттән аларның уку эшчәнлеген формалаштыру. Бу исә аларның уку һәм танып-белү мотивларын, максат куя белү һәм аны гамәлгә ашыру, уку нәтиҗәләрен бәяли алу күнекмәләрен үстерүне үз эченә ала. Шулай ук гамәлдәге осталыкларын заманча аралашу формаларына юнәлтүгә дә игътибар итә. Әлеге максатны тормышка ашыруга уен технологиясе куллануның роле зур. Ул чит телне өйрәнгән вакытта кызыксыну уятучы, дәртләндерүче фактор булып тора. Балалар дәресләрдә үзләрен ачып бетермәскә мөмкин, ә төрле уеннар вакытында моңа шартлар тудырыла. Балаларның, беренчедән, үз-үзләренә, икенчедән, үзләре янәшәсендәге кешеләргә ышанычлары арта.

Методик яктан дөрес уйланылган уен, бердән, укучыда туган телгә карата мәхәббәт тәрбияли, сөйләм күнекмәләрен үстерергә булыша, сөйләм эшчәнлеген табигый нормаларга якынайта, икенчедән, белем бирүнең коммуникатив юнәлеше таләпләренә җавап бирә.

Туган тел (татар теле) дәресләрендәге уен ситуацияләре яңа тел материалын презентацияләүдә, үтелгән лексик һәм грамматик материалны ныгыту һәм активлаштыруда аерым урын тота. Уенда парлап һәм төркем составында да катнашырга мөмкин. Бу вакытта сөйләмгә һәм аңа бәйле булмаган хәлдә дә катнашучылар бер-берсенә йогынты ясыйлар. Балаларда, табигый рәвештә нәрсәдер әйтү, нәрсә турында булса да сорау ихтыяҗы яки әңгәмәдәшенә җавап бирү теләге туа. Уеннар вакытында укучыларның белем һәм күнекмәләре камилләшә. Аларда бердәмлек, бер-берсенә ярдәм итү теләге туа. Балалар уен вакытында шатланырга, эшләгән

эшләреннән риза, канәгать калырга тиешләр. Уен барышында укучыларның сәләтләрен үстерү өстендә дә эшләргә кирәк.

Галим Г.К. Селенко максатчан юнәлеш буенча дидактик (белем дәрәҗәсен, танып белү эшчәнлеген киңәйтү, белем һәм күнекмәләрне гамәли эшчәнлектә куллану, гомумуку күнекмәләрен үстерү һ.б.); тәрбияви (мөстәкыйльлек тәрбияләү, билгеле бер юнәлешләр, дөньяга караш тәрбияләү һ.б); үстерелешле (игътибар, хәтер, сөйләм, фикерләүне, уку эшчәнлеген үстерү һ.б.); социальләштерә торган (аралашуга өйрәтү һ.б) уеннарны аера. Уку барышын интенсивлаштыруны активлаштыру максатында, уенны төшенчәләрне үзләштерү, теманы өйрәнү, яңа материалны аңлату, ныгыту, сөйләм эшчәнлегенең телдән төрләренә өйрәтү вакытында технология буларак файдаланырга була.

Балалар уены, аның сабый үсешенә тәэсире һәм роле турында психологлар Л.С. Выготский, А.А. Леонтьев, Д.Б. Эльконин һәм башкаларның хезмәтләре билгеле.

Педагогика һәм психология өлкәсендә укыту методы буларак, уен XX гасырның 70 нче елларында киң тарала. Укыту процессында уен технологиясе максатчан булуы белән гомуми уен эшчәнлегеннән аерылып тора. Хәзерге көндә мәктәпләрдә уку-укыту барышын активлаштыру һәм интенсивлаштыру максатыннан уен эшчәнлеге түбәндәге очракларда файдаланыла: 1) телне өйрәнүдә мөстәкыйль технология; 2) нинди дә булса технологиянең бер состав өлеше; 3) дәрес яки аның бер этабы (кереш өлеше, яңа белемнәрне ачу, рефлексия дәресе (катнаш дәрес), кабатлау һ.б.).

Дидактик уеннар әдәби уку дәресләрендә дә уңышлы файдаланыла ала. Мондый уеннар укучыларның сөйләмнәрен, иҗади активлыкларын үстерүгә, китап укырга кызыксыну уятуга, фантазияләрен баетуга хезмәт итәләр.

## Уеннарны оештыру һәм уткәрү үзенчәлекләре

Чит тел, милли мәктәптә рус теле дәресләрендә уен кулланунын күпьеллык практикасы телне өйрәнгәндә уен технологиясенең алыштыргысыз булуын раслый. Әмма дәрестәге уенның аны оештырганда исәпкә алынырга тиешле үзенчәлекләре бар:

1. Уен дидактика күзлегеннән чыгып төзелергә, көч җитәрлек булырга, катнашучылар тарафыннан үтәлерлек булырга тиеш.

2. Телне өйрәнергә омтылыш булдыру өчен, уенның кызыклы булуы да мөһим.

3. Уен барышында дустанә мөнәсәбәт, үзара ярдәмләшү атмосферасы, танып белү шатлыгы һәм соңгы нәтиҗә куанычы булу зарур.

Уеннар дәресне күңелле итеп үткәрергә, балада кызыксыну уятырга, иң авыр бирелә торган сүзләрне җиңел итеп аңлатырга ярдәм итә. Шуның белән бергә, уеннар балада иң кирәкле әхлакый сыйфатлар: гаделлек, күмәклек, логик фикерләү, мөстәкыйльлек, җитезлек тәрбияли.

Укучыларның белем, осталык, эш күнекмәләрен булдыру һәм үстерү максатыннан санамышлар, тизәйткечләр, җырлар, шигырьләр, табышмаклар, башваткычлар, мәкаль һәм әйтемнәр дә татарча сөйләшергә өйрәтүдә зур гамәли әһәмияткә ия булып тора. Бу биремнәр иҗади характерда булырга мөмкин. Дәресләрдә булсынмы, класстан тыш эшләр составындамы башваткычлар бер төрлелектән котылу чарасы булып тора.

## Телгә өйрәтү уеннарын классификацияләү

**Уен төрләре.** Уен вакытында кеше башка бернәрсә турында да уйламый, тик физик һәм эчке халәте генә хозурлана.

Уеннарның ике төре була: ачык кагыйдәле һәм яшерен кагыйдәле. Дидактик уеннар ачык, аңлаешлы кагыйдәгә керә.

О.С. Газман уеннарны түбәндәгечә квалификацияли:

*1. Хәрәкәтчән уеннар* кечкенәләрне һәм мәктәп чорындагы балаларны физик яктан тәрбияләүдә бик мөһим бер чара булып тора. Ул уйнаучылардан актив рәвештә хәрәкәтләнүне таләп итә. Мондый төрдәге уеннар балаларны иҗади яктан үстерә, бер-берсе белән көч сынашу теләген уята, бер команда булып эшли белүне, бер-береңә җаваплылыкны, ярдәм кулы суза белүне тәрбияли, дуслыкны ныгыта.

*2. Рольле уеннар (сюжетлы)* балаларга әхлаки тәрбия бирә, рухи яктан үстерә. Уенның сюжеты булып театр формасындагы бәйрәмнәр, карнаваллар, хезмәт элементлары кергән конструктор уеннар тора. Мондый уеннар вакытында балаларның фантазиясе яхшы эшли башлый. Бу төр уеннарның төп компонентлары булып тема, эчтәлек, ситуация, сюжет һәм рольләр тора.

Хәзерге заманда компьютер уеннары бик активлашып китте.

*3. Компьютер уеннары* – башка төр уеннарга караганда өстенлек итә торган уеннарның берсе. Бу төр уеннар балаларда төрле ситуациядә үз үзеңне тота белергә өйрәтә, тәҗрибә тупларга ярдәм итә. Мондый уеннар практик яктан аралаша белергә, эмоцияләрне белдерергә өйрәтә. Тик алар агрессив, куркыныч һәм шәфкатьсез булмаска тиеш.

Хәзерге вакытта уеннарны төркемләүдә В. Всеволодский-Гернгросс квалификациясе дә гамәлдә йөри. Ул барлык уеннарны 3 типологик төркемгә: драматик, спорт һәм орнаменталь (җырлы-биюле) уеннарга бүлә.

Җырлы-биюле уеннар нәниләр репертуарында сан ягыннан күп булмаса да, балалар (бигрәк тә кызлар) аларны яратып уйныйлар. Бу төр уеннарда музыка, җыр, такмак хәлиткеч роль уйный. Көй уен хәрәкәтләре белән тәңгәлләшә, җыр һәм такмакларның эчтәлеге хәрәкәтләрдә чагылыш таба.

Нәниләр репертуарында импровизацияле драматик уеннар да зур урын били. Бу уеннарның тематикасы киң, эчтәлекләре тормышның үзе

кебек күпьяклы. Алар яңа уеннарның барлыкка килүендә хәлиткеч урын тоталар. Традицион драматик уеннарның байтагы, тотрыклы форма һәм эчтәлек алганчы, шул уеннар рәтендә шомарган, камилләшкән дияргә нигез бар.

Балалар репертуарында спорт һәм зиһен сынашу уеннары зур урын алып тора. Билгеле булганча, аларның беренчеләре балаларның физик чыныгулары өчен әһәмиятле булса, икенчеләре исә, художестволы иҗат кәүсәсен үстерүгә буйсындырылганнар. Кыскасы, уен бала өчен нерв системасы, тән, акыл гимнастикасы булып хезмәт итә.

Укучыларның белем, осталык, эш күнекмәләрен булдыру һәм үстерү максатыннан санамышлар, тизәйткечләр, җырлар, шигырьләр, табышмаклар, башваткычлар, мәкаль һәм әйтемнәр дә татарча сөйләшергә өйрәтүдә зур гамәли әһәмияткә ия булып тора.

Формалары ягыннан уеннар телдән һәм язма уеннарга, өстәл һәм хәрәкәтле уеннарга бүленәләр.

Уен технологиясен уку-укыту барышында куллана башлаганчы, иң башта кайсы темаларны уен аша өйрәнү максатчан булуын ачыкларга кирәк. Уенны оештырганда, вакыт бүленешен төгәл билгеләү зарур, чөнки ял вакытларында уен кагыйдәләре бозылырга һәм уенның нәтиҗәлелеге түбән булырга мөмкин. Уеннар куллану балаларга тел материалын гамәли эшчәнлектә үзләштерергә булыша.

# Жырдай моңлы татар теле

## *«Туган тел» дәресе өчен уеннар*

Түбән сыйныфларда эшләгәндә гадәти биремнәргә дә уен элементлары кертеп җибәрү отышлы. Сүзләр белән бәйле күп төрле биремнәр балаларда кызыксыну уята.

**1** ***К*** **хәрефенә башланган кош атамалары яз.**

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| к | | | | | | | | |
| к | | | | | | | | |
| к | | | | | | | | |
| к | | | | | | | | |
| к | | | | | | | | |
| к | | | | | | | | |
| к | | | | | | | | |

**2** **Сүз эченнән яңа сүзләр тап. Бер сүз беткән хәрефкә икенчесе башлана.**

*Сүз эченнән 3 агач (куак) атамасын тап.*

баланаратал

*Сүз эченнән 3 чәчәк атамасын тап.*

кынакчәчәкыңгырау

*Сүз эченнән 3 үлән атамасын тап.*

бөтнекычыткannаратбаш

**3** ***К* хәрефенә тәмамланган кош атамалары яз.**

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | к | | | | |
| | | | | | к | | | |
| | | | | | к | | | |
| | | | | | к | | | |
| | | | | | к | | | |
| | | | | | к | | | |
| | | | | | | к | | |
| | | | | | | | к | |
| | | | | | | | к | |
| | | | | | | | | к |
| | | | | | | | | к |

**4** **Сүзләрнең синонимнарын яз.**

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| м | а | т | у | р | | | | | |
| | | | | | э | ш | ч | ә | н |
| т | а | т | л | ы | | | | | |
| | | | | | ж | и | т | е | з |
| п | ө | х | т | ә | | | | | |
| | | | | | | с | у | ы | к |
| к | у | а | н | а | | | | | |
| | | | | | | д | ә | ш | ә |

**5** **Сүзләрнең антонимнарын яз.**

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | к | е | ч | к | е | н | ә |
| с | а | л | к | ы | н | | | | |
| | | | | | | к | а | т | ы |
| с | а | р | а | н | | | | | |
| | | | | | | | а | я | з |
| я | л | к | а | у | | | | | |
| | | | | я | р | а | м | ы | й |

**6** **Яшерелгән сүзне тап.**

***Рука*** сүзен татарчага тәрҗемә ит. _________ .

**“у”** хәрефен нечкә пары белән алмаштыр. ________ .

***лес*** сүзен татарчага тәрҗемә ит.________ .

Сүзнең хәрефләрен түбәндәге тәртиптә яз:

**1243** __________. Кайсы хәреф артык калды? ___

**7** **Яңгырау тартыкларны сызсаң, нинди сүз килеп чыга?**

*дулкыртзучбы*

**8** **Сүзләрнең «киресен» яз.**

| | |
|---|---|
| ак | |
| килә | |
| көн | |
| белә | |
| җылы | |

**9** **Газетаны жил очырып алып киткән дә, анда кайбер сүзләр таралган. Аларны дөресләп яз.**

мөгбә ____________ икерш____________ выкан__________

**10** **Хәрефләрне урыннарына урнаштыр.**

утифл___________ мүкәлк__________ улыяк__________

рүкеб___________ тәйбүтә______________

**11** **Хәрефләрдән, дөрес итеп, өч сүз төзеп яз.**

**ә, т, т, й, ү, б, ә; ф, к, а, л, к, а; т, и, ч, к, е**

___________________ _________________ ______________

**12** **Йорт хайваннары һәм кошлары атамаларындагы сузыкларны яз:**

…т, …т, к…з, …рд…к, к…рк…, т…в…к, …т…ч

**13** **Иҗекләрне сүзләр килеп чыгарлык итеп тоташтыр.**

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *бал* | *ча* | |
| *та* | *кар* | *ка* | |
| *кур* | *сум* | *чак* | *чә* |
| *га* | *бак* | *чәк* | |

**14** ***Дару*** **сүзен, бер хәрефне алмаштыра барып,** ***сары*****га әйләндер.**

| | | | |
|---|---|---|---|
| д | а | р | у |
| | | | |
| с | а | р | ы |

15 *Арба* сүзен, бер хәрефне алмаштыра барып, *алка*га әйләндер.

| а | р | б | а |
|---|---|---|---|
| | | | |
| а | л | к | а |

16 *ш* белән мине ачып керәсең, *т* белән мине киясең.

| | | | |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|

17 Сүзләргә хрефләр өстәп, яңа сүзләр ясा.

өлкә

| | | | |
|---|---|---|---|

сары

| | | | | |
|---|---|---|---|---|

яка

| | | | | |
|---|---|---|---|---|

аяк

| | | | |
|---|---|---|---|

тар

| | | | |
|---|---|---|---|

Ы, Т, У, К, Н, Л

Хәрәкәтле, рәсемле, төрле карточкалар кулланып үткәрелә торган, күзәтүчәнлекне, логик фикерләүне үстерүгә юнәлдерелгән уеннар да дәресне жанландырып жибәрә.

18 **«Кем тизрәк укый? » уены**

Командаларга җөмләләре буталган текст бирелә.

**Текст**

*Чикләвек, миләш, балан өлгерә. Ул оясына чикләвек ташый. Миләш белән баланны да онытмый. Матур җәй артта кала. Кыш көне бу тәмле әйберләр кирәк була аңа. Урманга бай көз килә. Тиен малае Житез гөмбә киптерә.*

Укучылар, жөмләләр төзеп, хикәяне укырга тиеш. Текстны башкалардан тизрәк һәм дөрес итеп төзегән команда – жиңүче.

19 **«Кем җөмләне тизрәк таба?» уены**

Яшерелгән җөмләне уку өчен, саңгырау тартык авазларны һәм нечкә сузык авазларны сызарга кирәк.

## әтбалалар урасмәда уйкүныйөлар.

20 **«Алма жыю» уены**

Ике зур кәгазьгә “алма агачы” ясала. Ботакларга килеш исемнәре языла. “Алма”ларның артына төрле килештәге исемнәр языла. Сыйныф ике командага бүленә. Командалардан берәр укучы чыга. Алар, ярыша-ярыша, “алмаларын” ботакларга элә. Кем алдан элеп бетерә, шул жиңүче була.



**Алмаларга язу өчен сүзләр:**

шәһәрдә, авыл, елганы, мәктәптән, китапка, дус, малайның, урманнан, дәфтәрне, уенчык, Алиягә, бакчада

*(өйрәнелә торган лексик темага карап, төрле сүзләр бирелә)*

**21** **«Гөмбә җыю» уены**

Кәрзиннәргә хикәя фигыль заманнары языла. «Гөмбә»ләрнең артына төрле замандагы фигыльләр языла. Сыйныф ике командага бүленә. Командалардан берәр укучы чыга. Алар, ярыша-ярыша, «гөмбә»ләрне кәрзингә сала. Кайсы команда алдан җыеп бетерә, шул җиңүче була.



**Гөмбәләргә язу өчен сүзләр:**

Укый, килде, язмый, барачак, эшләмәде, кайтты, сикерә, җырлаячак, бии, йөгерде

*(өйрәнелә торган лексик темага карап, төрле фигыльләр языла)*

**22** **«Җиләк җыю» уены**

Кайбер җиләкләргә сүз, кайберләренә -лар/-ләр, -нар/-нәр кушымчалары языла. Укучылар ике командага бүленә. Һәр командадан укучылар чиратлап чыгып, сүзгә дөрес кушымчаны сайлап, кәрзингә салырга тиеш. Алдан бетергән команда җиңүче була. Җиләкләргә өйрәнелә торган лексик темага туры килгән сүзләр языла.

## 23 «Тылсымчы» уены

Укучыларга конвертлар таратыла. Ә анда – сүзләр язылган карточкалар. Шулардан дөрес итеп җөмләләр, алардан текст төзергә кирәк. Темалар төрле булырга мөмкин. Карточкада җөмлә башындагы сүз калын хәреф белән күрсәтелә, җөмлә ахырындагы сүз артыннан тыныш билгесе куелган була.

### Беренче командага сүзләр:

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Дөньяда** | бер | бака | яши. |
| **Ул** | сазлыкта | чебен | һәм |
| черки | ашый. | **Бервакыт** | кыр |
| үрдәкләр | сазлыкка | төшәләр. | |

### Икенче командага сүзләр:

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Әнисе** | бер | малайны | кибеткә |
| җибәрә. | **Ул** | ипи | казылык |
| сөт | катык | сатып | ала. |
| **Малай** | кибеттән | чыга. | |

## 24 Спорт диктанты.

Сыйныф өчәр кешедән торган командаларга бүленә. Командадагы һәр балага светофорның бер төсе бирелә (кечкенә төсле түгәрәкләр): яшел, сары, кызыл.

Һәр баланың үз функциясе бар. Яшел – укый; сары – тыңлый һәм кызылга барып әйтә, кызыл – яза. Командаларга текст бирелә.

**1 этап.** Яшелләр сарыга пышылдап тексттан 1 сүз укый. Сарылар аны йөгереп барып, кызылга әйтә. Кызыл ул сүзне яза. Шул рәвешле берәр сүз укый барып, текст тулысынча языла.

**2 этап.** Һәр команданың тексты тикшерелә. Кызыл текстны укый, ә яшел үзендәге кәгазьдән текстны тикшерә. Укытучы сүзләрнең дөрес язылуына да игътибар итәргә тиеш.

Диктантны тиз һәм дөрес язган команда җиңүче була.

Диктант өчен өйрәнелә торган лексик темадан чыгып, текстлар тәкъдим ителә.

## 25 «Сәяхәт» уены.

Сыйныфтагы укучылардан җидешәр баладан торган ике команда туплана. Ике командага да сүзләр таратыла. Һәр сүз язылган карточканың артына бер хәреф языла.

**Беренче командага сүзләр.**

| Татарстан | буйлап | сәяхәт - | ул | һәрвакыт |
|---|---|---|---|---|
| Т | И | М | Е | Р |
| онытылмас | маҗаралар | | | |
| Ю | Л | | | |

### Икенче командага сүзләр.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Юрий | мәгарәсе - | ул | әйтерсең | бер |
| В | О | К | З | А |
| табигать | музее | | | |
| Л | Ы | | | |

Командадагы укучылар сүзләрдән дөрес җөмлә төзергә һәм җөмләдәге сүзләр тәртибендә тезелеп басарга тиеш. Җөмләнең дөреслеген тикшерү өчен, укучылар карточкаларын кирегә әйләндерәләр. Андагы хәрефләрдән беренче команданың *тимер юл*, икенче команданың *вокзалы* сүзләре җыелса, командалар үз бурычларын дөрес үтәгән була. Дөрес һәм тиз итеп җөмлә төзи алган команда җиңүче була.

**26** **«Парыңны тап» уены.**

Укучыларга икегә аерылган мәкальләр таратыла. Мәгънәсенә карап бергә кушарга тиешләр.

| | |
|---|---|
| Акылсыз баш | кая барсаң да калмас |
| Баш – чәчсез, | кулың белән җыеп ала бел |
| Кара сакалың | авызыңны йом |
| Сакалга карама, | урман кошсыз булмас |
| Авызың белән чәчкәнне | кул батыр |

| | |
|---|---|
| Бер колагың йокласын, | аякка тынычлык бирми |
| Күз куркак, | акылга кара |
| Күзеңне йомма, | икенчесе тыңласын |

27 **«Яңа ел чыршысы» уены.**

Ике команда өчен ике чыршы әзерләнә. Һәр чыршыга бер шигырь языла. Төшеп калган сүзләр чыршы уенчыкларына языла. Сыйныф ике командага бүленә. Укучылар чиратлап чыгып, төшеп калган сүзләрне тиешле урынга урнаштырырга тиешләр. Алдан бетергән команда җиңүче була.

**Беренче команда өчен шигырь:**

**Кыш бабай кәнфитләре**

Яшел чыршы тирәли
Бастык ....   ясап.
Яңа елны дуслар белән
Каршыларбыз ... .
Чыршы матур бизәлгән,
Бәйрәмебез бик ... .
Кыш бабай бүләк өләшә,
Кәнфитләре бик ... .

*(Резеда Фәрхетдинова)*

**Икенче команда өчен шигырь:**

**Декабрь**

Ай-яй салкын!» – ди Кәбирә.
«Туңдыра бит!» – ди  ...  .
Кулны-битләрне чеметә
Ник шундый ул ... .
«Ал чаңгыңны!» – ди Кадыйрә.
«Киттек тауга!» – ди Кадыйр.
Җитез  .... , чаңгы шусаң,
Ягымлы ул ... .

*(Илдар Юзеев)*



**Чыршы уенчыкларына язу өчен сүзләр:**

Декабрь, түгәрәк, тәмле, бергәләп,
ямьле, декабрь, Кәбир, булсаң.

**28** **Сабантуйга бәйле рәсемнәрне кара һәм парларын табып яз.**












  

 

**29** **Бу фигурада текст яшерелгән. Текстның башын тап һәм аны күчереп яз.**

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| б | у | у | к | у | ч | ы |
| е | **р** | **е** | **б** | **л** | **у** | **у** |
| н | **к** | **у** | **а** | **т** | **я** | **л** |
| ч | **ы** | **й** |  | **с** | **и** | **С** |
| е | **к** | **л** | **а** | **с** | **ф** | **о** |

**30** **Яшерелгән хайван атамаларын тап.**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| а | ю | б | ү | е |
| т | к | е | р | п |
| т | у | т | е | о |
| и | я | ө | л | ш |
| е | н | е | к | и |

**31** **Бу фигурадан 6 сыйфатны тап.**

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| м | а | т | у | р | к | о |
| с | н | а | з | ж | ы | я |
| а | ы | я | ә | ы | л | ш |
| л | к | з | ң | г | ә | р |

## 32 Ребусны чиш.

н ә

‘ ‘ ш ’ а ‘ ’ 243



АМ

## 33 Бу серле фигурада 4 сүз яшерелгән. Аларны яз. Калган хәрефләрдән тагын бер сүз төзе.

| | | | |
|---|---|---|---|
| т | и | е | н |
| ө | р | н | м |
| л | а | у | |
| к | у | я | н |
| е | л | а | н |

## 34 Түбәндәге алгоритмны кулланып, җавапны тап.

1) Тексттан артык хәрефләрне тап.
2) Артык дип санаган хәрефләрне сыз.
3) Килеп чыккан текстны яз.

Чыпнчыкнларн – төрнлен шартнларндан яншәрнгән җайнлашнканн кошнларн. Анларн көньякнтан дан, Сенберндән дән, Афнринкан һәмн Анменринкандан дан яншинләрн.

35 ***Б*** **хәрефенә башланган сүзләрдән генә торган әкият яз.**

Бер бала бакчага бара...

## Әдәбият дөньясына сәяхәт

### *«Әдәби уку» дәресе өчен уеннар*

**1** **«Парын тап» уены**

Укучыларга мәкаль-әйтемнәр язылган карточкалар таратыла. Һәр мәкаль ике өлешкә бүленеп, ике карточкада тәкъдим ителә. Укучылар мәкальнең башын һәм ахырын табып бергә кушалар һәм мәгънәсен аңлаталар.

**2** **«Мәкаль-әйтемне дөрес яз» уены**

Бирелгән сүзләрдән мәкаль-әйтем төзеп язарга тәкъдим ителә.

Мәсәлән:

1) зур, белем, иң, байлык, дөньяда

2) Түгел, илдә, көч, бездә

**3** **«Мәкаль-әйтемне җыеп бир» уены**

Мәкаль-әйтемнәрнең ике өлешен туры китереп язарга кирәк.

Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| Аз сөйлә | телсез сандугач |
| Илсез кеше | акылы кыска булыр |
| Теле озын кешенең | күп эшлә |

**4** **«Исемен тап» уены**

Укучыларга төрле төсләр белән сүзләр язылган плакат тәкъдим ителә. Әлеге сүзләрдән укыган әсәрләрнең исемнәрен төзеп әйтергә кирәк була.

**5** **«Исемен уйлап әйт» уены**

Ачкыч сүзләр ярдәмендә әсәрнең исемен уйлап әйтергә кирәк.

Мәсәлән:

1) озын чәч, су, тарак, кыяфәтсез

2) Өстәл, карбыз, кавын, кяр, алма, көз

### 6 «Кем язган?» уены

Укучыларга тема кысаларында өйрәнелгән әсәрләрдән өзекләр язылган карточкалар таратыла. Максат – аларны сәнгатьле итеп көндәш командага укып чыгу. Алар авторның исемен әйтергә тиеш булалар.

### 7 «Мин кайдан?» уены

Укытучы укылган әсәрләрдән предметлар яки сюжетлы рәсемнәр күрсәтә. Укучылар әсәрләрнең исемнәрен әйтергә һәм эчтәлекләрен кыскача сөйләргә тиеш булалар.

### 8 «Рәсем буенча сөйлә» уены

Әлеге уенда балаларның укылган әсәрләре буенча үзләре ясаган рәсемнәре файдаланыла. Укучылар теләсә кемнең рәсемен алып әлеге әсәр турында сөйләргә тиеш була.

### 9 «Артык сүз» уены

Укучыларга бирелгән сүзләр рәтендә әсәрдә күзәтелмәгән артык сүзне (предмет-күренешне) табып әйтергә кушыла.

Мәсәлән:

1) агач төпләре, яфрак, су, тамырлар, кәҗә, эти, әни, бүре, дару, яз

2) Искәндәр, газета кәгазе, Акбай, ипи телеме, сабын, дача, сөлге, койма

**10** **«Әкиятнең исемен әйт» уены**

Укытучы әдәби әкиятләрдән өзекләр укый. Укучылар әкиятнең авторын һәм исемен әйтергә тиеш булалар.

1) *«Әби аларны ашатырга тотынса: «Җимне миңа әзрәк бирдең», «Ник минем өлешемә кердең?» – дип кычкырыша башлыйлар икән әтәчләр. Әйтешеп кенә калмыйлар, шунда ук сугыша да башлыйлар икән».*

2) *Китте болар. Бара болар, һаман бара, –*
*Күренмидер күзләренә ак һәм кара.*
*Бара болар. Күпме баргач, Алла белә,*
*Юл өстендә үлгән бүре башын таба.*

**11** **«Буталмыш» уены**

Шигырьдә буталып бирелгән юлларны тиешле тәртиптә төзеп язарга.

Мәсәлән:

Их, кыз буласым калган!
Кызларга кадер-хөрмәт.

Эшләре бара гөрләп:
Белмәдем шул мин алдан.
Чәчәк бүләк итәсең.
Бәйрәм саен аларга

Ишек ачып кертәсең.
Исәнләшеп үтәсең,
Хәтта портфельләрен дә
Күтәрешеп йөртәсең.

Автобуста барганда

Троллейбуста барганда,

Ә син утырып кара!

Алар утырып бара.

*Р. Миңнуллиннан*

**12** **«Шигырьне дәвам ит» уены**

Мәсәлән:

1) *Жыр күтәрә күңелне,*

*Бар да көләч, шат бүген.*

2) *Скрипка кылларыдай*

*Тартылганнар чыбыклар,*

**13** **«Әсәрне тәмамла» уены**

Әсәрнең ахыры бирелмәгән өлешен укырга тәкъдим ителә, шуның ахырын уйлап язарга кушыла. Соңыннан укучылар әсәрнең язучы иҗат иткән ахыргы өлеше белән чагыштыралар.

**14** **«Геройларга булыш» уены**

Укытучы укучыларга әсәрнең эчтәлегеннән чыгып, геройларга катлаулы ситуацияләрдән чыгу юлын табу өчен план төзергә тәкъдим итә:

Мәсәлән:

«Тукран малае Шуктуган» әсәрен укыганда түбәндәге сорауга җавап бирергә кушыла:

*«Сезнең фикерегезчә, Шуктуганга хаталар ясамас өчен нишләргә тәкъдим итәр идегез?»*

**15** **«Күмәк хикәя» уены**

Укытучы укучыларга билгеле бер темага күмәкләшеп хикәя төзергә тәкъдим итә. Һәр бала алдагысы белән бәйле булган бер җөмлә әйтә. Шул рәвешле хикәя төзелә.

**16** **«Серле чемодан» уены**

Төркемнәрдә уйнатып була. Укытучы укучыларга әйбер-предметлар буенча чемоданның иясе кайсы герой булуын билгеләргә тәкъдим итә. Мәсәлән: Кармак, балык, тәкыя, кашкарый.

**17** **«Кайсы персонаж» уены**

Буталган сүзләр буенча персонажларны уйлап әйтергә кушыла.

Гантушук

Кәбилнеч

**18** **«Сүзне кем беренче таба» уены**

Укытучы бер сүз әйтә, укучылар шул сүзне текстта табып алдагы сүз белән укып бирергә тиеш булалар. Сүзләрне иң күп тапкан укучы җиңүче була.

**19** **«Әдәби лото» уены**

Бирелгән сүзләрнең кайсы геройныкы икәнлеген ачыклап шакмакларны ябып барыга кушыла.

«Әйдә, улым, тизрәк, кил минем яныма! Урманны коткарырга булыш!»;

«Безнең урманны корткыч хәшәрәтләр басып алды. Алар агач яфракларын ашап бетерделәр. Җәнлекләргә тукланырга азык, сыенырга куак калмады, шуңа күрә алар бу урманны ташлап киттеләр. Синең бабаң барча кошларын җыярга, шулар белән хәшәрәтләрне юк итәргә китте. Ә син, Шуктуган, кайда булдың бик озак?»;

«Һә-әй, энем! Минем бу томшыгым җир астында кайда нинди корт, нинди суалчан кыймылдаганын да ишетә ала. Ә синеке озын булса да андый сизгер түгел. Шуңа күрә тота алмыйсың...»;

«Минем телем синеке кебек кыска түгел шул. Менә күр: ул шундый озын, җитез һәм ябышкак. Бер генә чебен-черки дә, бер генә бөҗәк тә аннан ычкына алмый»;

«Әйдә, сынап карыйк. Тик менә синең бу озынтомшыгың андый эшкә ярар микән? Бу томшыгың белән сиңа бөҗәкләрне кайры астыннан казып чыгару уңайлырак. Аннары синең минеке име колакларың да юк бит»;

«Тагын кайры каезларгамы?! Алай интеккәнче, ярканат янына баруым яхшырак. Ул мине, томшык авырттырмый-нитми генә, бөҗәкләр тотарга өйрәтер. Күрерсең менә, очып барган уңайга гына мин аларның йөзесен, меңесен эләктерермен».

## 20 «Хатаны куып тот» уены

Укытучы әдәби текстны аерым сүзләрне үзгәртеп укый. Укучылар игътибар белән карап барып, хатаны тапкач, укытучыны туктатып хатаны төзәтәләр. Иң күп хатаны күргән укучы җиңүче була.

## 21 «Мине тап» уены

Текстның күрсәтелгән өлешеннән

- исем сүз төркеменә караган сүзләрне
- сыйфат сүз төркеменә караган сүзләрне
- фигыль сүз төркеменә караган сүзләрне
- алмашлык сүз төркеменә караган сүзләрне

табарга кушыла.

### 22 «Уйлап чиш» уены

Геройларның исемнәрен уйлап әйтергә кушыла. Укучылар аларны нәрсә берләштергәнен әйтәләр.

Ганшукту, каярнат, пекер, дишөл, каба

### 23 «Тузгыган юллар» уены

Укытучы кышкы буран туздырган шигырь юлларын дөрес итеп урнаштырырга куша.

Мәсәлән:

тарак ялтырый алтын көнгә кулындагы каршы

### 24 «Сүзне алыштыр» уены

Тактага беренче баганага укучыларга аңлаешлы булган сүзләр языла, икенче баганада аларның «туганнар»ы урын ала. Асоциацияләр, чагыштыру буенча укучылар аларны парлаштырырга тиеш булалар.

| | |
|---|---|
| Болын | киңәшче, иптәш |
| Китап | пешертә коймаклар |
| Бәйрәм | уйнаклап йөри колын |

## 25 «Кайсы яхшы, кайсы начар» уены

Укытучы укучыларга бер предмет күрсәтә, яки күренеш әйтә, укучылар ике төркемгә бүленеп шуның яхшы якларын һәм җитешсезлекләрен әйтәләр.

Мәсәлән:

сәгать

| **Беренче төркем** | **Икенче төркем** |
|---|---|
| Сәгать матур, аның цифрлары алтыннан йөгертелгән. | Тиз йөри, безне ашыктыра |
| Ул вакытны дөрес билгеләргә ярдәм итә. | Ул ватылып туктарга мөмкин. |

## 26 «Шифровка» уены

1) Әсәрнең исемен шифрларны чишеп уйлап әйтергә кушыла

| | **1** | **2** | **3** | **4** |
|---|---|---|---|---|
| **А** | ш | к | п | һ |
| **Б** | ы | р | е | и |
| **В** | д | ш | о | к |
| **Г** | м | с | ә | е |

**А2 Б1 А1  А4 Г3 Г1  В4 Б3 В2 Г4**

2) Татар алфавитында хәрефләрнең тәртибен искә төшереп әсәрнең исемен (авторы) уйлап әйтергә кушыла.

Мәсәлән:

**17, 7, 30, 14, 2, 3, 12, 15**

**27** **«Кояш» уены**

Уртада түгәрәк бирелә. Биредә дәрестә өйрәнелә торган (әсәрдә булган) тема / әдәби герой язылып куела. Кояшның нурлары булып теманы ачып биргән сүзләрне / геройның характер сыйфатларын язып куярга кушыла.

**28** **«Тәлгәш» уены**

Тәлгәштәге җимешләргә әдәби геройның характер сыйфатлары язып куела. Шулар буенча укучыларга геройны уйлап әйтергә кушыла.

**29** **«Ун сүз» уены**

Укытучы әсәрдән алынган ун сүздән торган җөмлә укый. Кем тизрәк әсәрнең исемен атый, шул җиңүче була.

Мәсәлән:

*1) Әти-әнисе җир казып яткан арада, малай каядыр юкка чыккан.*

*2) Карават янында мәктәп сумкасы тотып торган әбисе малайның аякларыннан сөйде.*

**30** **«Сүзне әйтеп бетер» уены**

Укучыларга соңгы сүзе төшеп калган шигъри дүртьюллыклар язылган карточкалар таратыла. Укучылар сүзне әйтергә тпиеш булалар.

Мәсәлән:

*Җәйге җылы яңгыр ява,*
*Әкрен генә җил дә исә,*
*Күңелләрне сөендереп,*
*Яңгыр суын эчә-эчә,*
*Без утырткан урман …*

### 31 «Син кем яклы?» уены

Әлеге уен әдәби герой шәхесенә анализ ясалганда кулланыла. Укучыларга үз позициясен тәгъбир итәргә ярдәм итә. Әсәрдге ике герой алына. Укучылар әсәрдән өзекләр, тормыштан мисаллар китереп үз позицияләрен якларга тиеш булалар.

### 32 «Тере рәсемнәр» уены

Укучылар әдәби әсәрдән билгеле бер өзек тыңлаганнан яки укыганнан (яки уку, тыңлау барышында) соң әлеге эпизодны сүзсез күрсәтеп бирергә (мизансцена төзергә) тиеш булалар.

### 33 «Иләк» уены

Укытучы бирелгән сүзләрдән (геройның характер сыйфатларыннан; яхшы сыйфатлардан начар сыйфатларны; төрле вакыйгалардан әсәрдә тасвирланганнарны һ.б.) аерып чыгарырга куша.

### 34 «Зирәк агач» уены

Игътибар белән текст укыла. Укучылар аның буенча сораулар язалар. Ул сораулар язылган язулар агачка беркетелеп эленә. Укучылар чиратлашып агачтан бу язуларны алып укыйлар һәм андагы сорауга җавап бирәләр. Калганнар сорауны һәм аңа җавапны бәялиләр. Ахырдан әсәрне иң яхшы белүчеләр – җиңүчеләр билгеләнә.

### 35 «Синоним уйла» уены

Укытучы берәр әдәби геройны, аның төп характер сыйфатын атый. Укучылар шул сүзгә синонимнар әйтергә тиеш булалар.

Мәсәлән:

Бүре усал

### 36 «Әкиятне үзгәртеп яз» уены

Укытучы укучыларга әкиятне үзгәртеп язарга куша. Шуннан соң иң яхшы һәм кызыклы, оригиналь, креатив булган әкият билгеләнә.

### 37 «Әкият-мәкаль» уены

Укучыларга бер мәкаль бирелә, шуның буенча әкият язарга кушыла.

Әлеге уен укучыларның иҗади активлыгын, образлы фикерләүләрен үстерә, фантазияләрен баета.

### 38 «Кайсы әкияттә?» уены

Укытучы мәкаль әйтә, укучылар шул мәкальгә туры килгән әкиятне атарга тиеш булалар.

### 39 «Булмас хәл» уены

Укытучы кәгазьдә билгеле бер әсәрнең темасына туры килә торган фраза яза, укучыга күренмәсен өчен язылган урынны бөкләп бирә. Укучы үз фразасын әйтә. Биредә бер шарт үтәлергә тиеш. Әлеге фразалар билгеле бер сорауларга җавап рәвешен алырга тиешләр.

Мәсәлән:

Ул кем? Аның төс-кыяфәте нинди? Ул кая бара? Аңа нәрсә диләр? Ул ничек җавап бирә? Бу хәл ничек тәмамлана?

Ахырдан укытучы бөкләнгән урыннарны ачып текстны тоташ укый һәм кәгазжждә язылган булмас хәлне укып күрсәтә.

### 40 «Шифрлаучы» уены

Укучыга берәр әкиятне яки зур булмаган хикәяне шифрларларга тәкъдим ителә, аның схема рәвешендә күрсәтергә кушыла (мәсәлән, геометрик фигуралар кулланырга мөмкин).

Мәсәлән:

«Шүрәле» әкиятендә Батыр белән Шүрәле образларын турыпочмак (Батыр) белән ромб (Шүрәле) геометрик фигуралары ярдәмендә күрсәтергә мөмкин. Укучылар нинди әсәр икәнлеген әйтеп бирергә тиеш булалар.

**41** **«Әйберләр белән булган кызыклы хәлләр» уены**

Укучыларга тирә-яктагы бер әйбере сайлап алып (чәйнек, энә, китап, карандаш, кашык, сабын һ.б.) шуның турында кызыклы хәлләр уйлап язырга тәкъдим ителә.

**42** **«Авторны әйт» уены**

Укучыларга язучыларны биографиядән кызыклы фактлары буенча билгеләргә тәкъдим ителә.

**43** **«Кайнар урындык» уены**

Укучы урындыкка тактага арты белән утыра. Укытучы яки башка укучы тактага әсәр героеның исемен яза. Укучылар геройның исемен әйтмичә, аңа характеристика бирәләр, урындыкта утырган укучы геройны дөрес билгеләргә тиеш була. Җавап бирә алмаган саен урындык «кыза».

**44** **«Мин – язучы» уены**

Укучылар язучы булып карыйлар. Үзләрен билгеле бер вакытта йорт хайваны яки кыргый хайван итеп күз алдына китерергә тиеш булалар. Үзе турында зур булмаган «Минем тормышымнан бер көн» дигән темага хикәя төзергә тәкъдим ителә. Биредә сораулар биреп куярга мөмкин.

Мәсәлән:

Синең хуҗаң кем? Аның сиңа мөнәсәбәте нинди? Син кайда йоклыйсың? Нәрсә ашыйсың? Көндез нишлисең.

**45** **«Начар-яхшы» уены**

Яхшы персонажлар аталганда укучылар кул чабарга, тискәре персонажлар әйтелгәндә тыпырдарга тиеш булалар.

**46** **«Геройларны әсәрләре буенча озатып чык» уены**

Төркемнәрдә уйнала. Укучыларга герой исемнәре язылган карточкалар таратыла, аларны әсәрләр буенча дөрес урнаштырырга кирәк була.

**47** **Кроссвордны чишкәч, сез татар халык авыз иҗатының бер төрен табарсыз.**




*1.Тирән мәгънәле, тәҗрибәгә нигезләнгән әйтемнәр.*

*2. Әни һәм аның кызлары турындагы әкият.*

*3. “Шүрәле” әкиятендә Батыр урманга көннең кайсы вакытында китә?*

*4. Әкиятләрдә иң куркак саналучы җәнлек.*

*5. “Су анасы” әкиятендә басмада онытылган әйбер.*

*6. Әкиятләрдә иң хәйләкәр җәнлек.*

*7. Татар халык  җыры. Кыз кеше исеме.*

*8. Бармагы бүрәнә ярыгына касылып калган әкият герое.*

**48** **Кроссворд сорауларына җавап тапсагыз, Шуктуган турында күбрәк белерсез.**




*1. Шуктуган агач кортларын  нәрсә ярдәмендә чистарта?*

*2. Шуктуган кайда яши?*

*3. Шуктуган нинди кош ул?*

*4. Шуктуганның бабасының исеме ничек?*

*5. Шуктуган агач тишегендә яши,  агач тишеген икенче төрле ничек әйтеп була?*

*6. Шуктуган нәрсәләрне корткычлардан коткарырга булыша?*

*7. Тук-Тук бабайның оясы нинди агачта?*

*8. Юкә агачын нинди кортлар кимерә?*

## 49 Кросвордны чишү, сезгә бәхет ачкычларын табарга ярдәм итәр




1. *Түземле, үзен бик тыныч тота белүче.*
2. *Тәрбияле, итәгатьле.*
3. *Яхшылыкны бәяли белүче.*
4. *Яхшы күңелле, ярдәмчел.*
5. *Әдәпле, тәртипле.*
6. *Киң күңелле, миһербанлы.*
7. *Ихтирамлы, ярдәмчел, хөрмәт күрсәтүче.*

## 50 Геройларны «киендерү» уены.

Аерым бер әсәр укыгач, укучыларны төркемнәргә бүлеп, һәр төркемгә бер геройның төссез рәсеме (төлке, бүре, аучы кебек әкият геройлары яки Шәвали, Айсылу һ.б.) бирелә. Сайлап алу өчен төрле киемнәр, һәм аларның холкын тасвирлый торган сыйфатламалар язылган кәгазьләр куела. Укучылар башта геройны төрле киемнәргә киендерәләр (әсәрдә тасвирланганча),

аннары геройны тасвирлый торган сыйфатларны аның тирәсенә ябыштырып чыгалар. Мәсәлән,  Ш. Галиевнең «Мин» шигырен укыгач, Шәвалине татар егете итеп киендерәләр, *кире, юаш, тәрбиясез, үткен, тапкыр, җитез, тыйнак, шук, җыйнак* сүзләре арасыннан  **үткен, тапкыр, җитез,  тыйнак, шук, җыйнак** сүзләрен сайлап алып аны бәялиләр.

**51** **Кроссвордны чишкәч, сез  Шәвәлинең кая ашыгуын белерсез.**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | |
| | 2 | | | | | | |
| | | 3 | | | | | |
| 4 | | | | | | | |
| | 5 | | | | | | |
| 6 | | | | | | | |
| | | 7 | | | | | |
| | 8 | | | | | | |

*1.Татар халкының яз көне була торган иң зур бәйрәме.*

*2.  Ел фасылының иң җылы вакыты.*

*3.  “Өй”  сүзенең синонимы.*

*4.  Агачның “киеме”.*

*5.  Язу  өчен агачтан ясала.*

*6. Көтүченең эш коралы.*

*7.  Матур сүзенең синонимы.*

*8. Иң матур, еш бүләк ителә торган әйбер.*

**52** **Кроссворд сорауларына җавап тапсагыз, үзегезнең иң якын сердәшчегез белән очрашырсыз.**




1. *Ничек эшләргә белмәгәндә ярдәм сүзе.*
2. *Иң кечкенә балалар да яратып тыңлый торган хикәят.*
3. *Дус сүзенең синонимы.*
4. *Кешенең фикерләү сәләте.*
5. *Тәрбияле, итәгатьле сүзләренең синонимы.*

**53** ***Рәсемнәр ярдәмендә табышмакларның җавапларын тап.***







1) Сакалы бар, акылы юк.

2) Бүре түгел – көрән,

Куян түгел – озын колаклы,

Ат түгел – тояклы.

3) Кешенең дусты, йортның сакчысы.

4) Канаты бар,

Аягы бар, –

Йөзә алмый.

5) Йомры, йомшак сары йомгак

Йөгереп йөри чирәмдә.

## Җаваплар

**1.10 К хәрефенә башланган кош атамалары яз.**

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| к | а | З | | | | | | |
| к | ү | к | е | | | | | |
| к | а | р | г | а | | | | |
| к | о | з | г | ы | н | | | |
| к | ө | р | т | л | е | к | | |
| к | ү | г | ә | р | ч | е | н | |
| к | а | р | а | б | ү | р | е | к |

**2.10. Сүз эченнән яңа сүзләр тап. Бер сүз беткән хәрефкә икенчесе башлана.**

*Сүз эченнән 3 агач (куак) атамасын тап.*

балан, нарат, тал

*Сүз эченнән 3 чәчәк атамасын тап.*

кына, акчәчәк, кыңгырау

*Сүз эченнән 3 үлән атамасын тап.*

бөтнек, кычыткан, наратбаш

**3.11. К хәрефенә тәмамланган кош атамалары яз.**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **ү** | **р** | **д** | **ә** | **к** | |
| **л** | **ә** | **к** | **л** | **ә** | **к** |
| **ч** | **ы** | **п** | **ч** | **ы** | **к** |
| **к** | **ә** | **к** | **к** | **ү** | **к** |
| **п** | **е** | **с** | **н** | **ә** | **к** |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **я** | **б** | **а** | **л** | **а** | **к** | | | |
| **к** | **ө** | **р** | **т** | **л** | **е** | **к** | | |
| **а** | **к** | **ч** | **а** | **р** | **л** | **а** | **к** | |
| **т** | **ә** | **к** | **ә** | **р** | **л** | **е** | **к** | |
| **б** | **ы** | **т** | **б** | **ы** | **л** | **д** | **ы** | **к** |
| **к** | **а** | **р** | **а** | **б** | **ү** | **р** | **е** | **к** |

## 4.11. Сүзләрнең синонимнарын яз.

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| м | а | т | у | р | *г* | *ү* | *з* | *ә* | *л* |
| *т* | *ы* | *р* | *ы* | *ш* | э | ш | ч | ә | н |
| т | а | т | л | ы | *б* | *а* | *л* | *л* | *ы* |
| *ө* | *л* | *г* | *е* | *р* | җ | и | т | е | з |
| п | ө | х | т | ә | *ч* | *и* | *с* | *т* | *а* |
| *с* | *а* | *л* | *к* | *ы* | *н* | с | у | ы | к |
| к | у | а | н | а | *с* | *ө* | *е* | *н* | *ә* |
| *ч* | *а* | *к* | *ы* | *р* | *а* | д | ә | ш | ә |

## 5.12. Сүзләрнең антонимнарын яз.

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *з* | *у* | *р* | к | е | ч | к | е | н | ә |
| с | а | л | к | ы | н | *җ* | *ы* | *л* | *ы* |
| *й* | *о* | *м* | *ш* | *а* | *к* | к | а | т | ы |
| с | а | р | а | н | *ю* | *м* | *а* | *р* | *т* |
| *б* | *о* | *л* | *ы* | *т* | *л* | *ы* | а | я | з |
| я | л | к | а | у | э | *ш* | *ч* | *ә* | *н* |
| *я* | *р* | *ы* | *й* | я | р | а | м | ы | й |

**6.12. Яшерелгән сүзне тап.**

*Кул – күл*

*Урман – урам. Артык хәреф – н*

**7.12. Яңгырау тартыкларны сызсаң, нинди сүз килеп чыга?**

***укытучы***

**8.13. Сүзләрнең «киресен» яз.**

| | |
|---|---|
| ак | кара |
| килә | китә |
| көн | төн |
| белә | белми |
| җылы | салкын |

**9.13. Газетаны жил очырып алып киткән дә, анда кайбер сүзләр таралган. Аларны дөресләп яз.**

гөмбә, кишер, кавын

**10.13. Хәрефләрне урыннарына урнаштыр.**

туфли, күлмәк, яулык, бүрек, түбәтәй

**11.13. Хәрефләрдән дөрес итеп өч сүз төзеп яз.**

түбәтәй, калфак, читек

**12.14. Йорт хайваннары һәм кошлары атамаларындагы сузыкларны яз:**

ат, эт, каз, үрдәк, күркә, тавык, әтәч

**13.14. Иҗекләрне сүзләр килеп чыгарлык итеп тоташтыр.**

*курчак, карга, бакча, чәчәк, сумка, балта*

**14.15.** ***Дару*** **сүзен, бер хәрефне алмаштыра барып,** ***сары*га әйләндер.**

| | | | |
|---|---|---|---|
| **д** | **а** | **р** | **у** |
| **д** | **а** | **р** | **ы** |
| **с** | **а** | **р** | **ы** |

**15.15.** ***Арба*** **сүзен, бер хәрефне алмаштыра барып,** ***алка*га әйләндер.**

| | | | |
|---|---|---|---|
| **а** | **р** | **б** | **а** |
| **а** | **р** | **к** | **а** |
| **а** | **л** | **к** | **а** |

**16.15.** *ш* белән мине ачып керәсең, *т* белән мине киясең.

| | | | |
|---|---|---|---|
| и | ш | е | к |

| | | | |
|---|---|---|---|
| и | т | е | к |

**17.15. Сүзләргә хрефләр өстәп, яңа сүзләр яса.**

өлкә**н** **таяк** сары**к** тар**ы** **ялкау**

**2.27.** 1) Дөньяда иң зур байлык – белем

2) Бездә түгел, илдә көч

**5. 27.** 1) Г. Тукай «Су анасы»

2) Ф. Яруллин «Күзгә табын»

**9.28.** 1) З. Әхмәров «Агачлар да авырый». Артык сүз – бүре.

2) М. Мәһдиев «Чисталык өчен көрәш». Артык сүз – сөлге.

**10. 29.** 1) А. Алиш. «Чукмар белән Тукмар» әкияте

2) Г.Тукай. «Кәҗә белән сарык» әкияте

**12. 30.** 1) Бүген Әни бәйрәме,

Сигезенче март бүген.

*2)* Шул кылларда көй уйныйлар

Композитор чыпчыклар.

**16.31.** Э. Шәрифуллина «Алтын балык»

**17.31.** Нечкәбил Шуктуган

**19.31.** шөлди, Тук-тук бабай, ярканат, бака, керпе, Шуктуган

**22.33.** Шуктуган, ярканат, керпе, шөлди, бака – «Тукран малае Шуктуган» әкияте геройлары.

**23.33.** Г.Тукай. «Су анасы»

Көнгә каршы ялтырый кулындагы алтын тарак

**26.34.** 1) Б. Рәхмәт. «Кыш һәм кеше»

2) Нечкәбил

**29.35.** 1) Мәһдиев М. «Чисталык өчен көрәш»

2) А.Әхмәтгалиева. «Әби, Илнур һәм шигырь...»

**30.35.** үсә

**35.36.** ачулы, ерткыч, куркыныч һ.б.

**47.39. Кроссвордны чишкәч, сез татар халык авыз иҗатының бер төрен табарсыз.**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 м | **ә** | к | а | л | ь |
| 2 ө | ч | | **к** | ы | з | | |
| | | 3 к | **и** | ч | | | |
| | 4 к | у | **я** | н | | | |
| | | | 5 **т** | а | р | а | к |
| | 6 т | ө | **л** | к | е | | |
| | | | 7 **Ә** | п | и | п | ә |
| | 8 Ш | ү | **р** | ә | л | е | |

**48.40. Кроссворд сорауларына җавап тапсагыз, Шуктуган турында күбрәк белерсез.**

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 т | о | м | **ш** | ы | к | | |
| | | | | | 2 **у** | р | м | а | н |
| | | | 3 т | у | **к** | р | а | н | |
| | 4 Т | у | к | | **т** | у | к | | |
| | | | | 5 к | **у** | ы | ш | | |
| | | | | 6 а | **г** | а | ч | | |
| | | | | 7 н | **а** | р | а | т | |
| 7 к | и | с | м | ә | **н** | | | | |

**49.41. Кросвордны чишү, сезгә бәхет ачкычларын табарга ярдәм итәр.**

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 с | а | **Б** | ы | р | | | | | | |
| | | | 2 **Ә** | д | ә | п | л | е | | | |
| | 3 р | ә | **Х** | м | ә | т | л | е | | | |
| 4 к | е | ш | **Е** | л | е | к | л | е | | | |
| | | | 5 **Т** | ә | р | б | и | я | л | е | |
| 6 и | г | е | **Л** | е | к | л | е | | | | |
| 7 к | е | ч | **Е** | | к | ү | ң | е | л | л | е |

**51.42. Кроссвордны чишкәч, сез Шәвәлинең кая ашыгуын белерсез**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 с | а | **б** | а | н | т | у | й |
| | 2 ж | **ә** | й | | | | |
| | | 3 **й** | о | р | т | | |
| 4 я | ф | **р** | а | к | | | |
| | 5 к | **ә** | г | а | з | ь | |
| 6 к | а | **м** | ч | ы | | | |
| | | 7 **г** | ү | з | ә | л | |
| | 8 ч | **ә** | ч | ә | к | | |

**52.53. Кроссворд сорауларына җавап тапсагыз, үзегезнең иң якын сердәшчегез белән очрашырсыз.**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 1 **к** | и | ң | ә | ш |
| | 2 ә | к | **и** | я | т | | |
| | 3 и | п | **т** | ә | ш | | |
| | | | 4 **а** | к | ы | л | |
| 5 ә | д | ә | **п** | | | | |

**53.43.** Кәҗә, ишәк, эт, тавык, чеби

## Татар теле дәресендә QR-квест

Традицион, бер төрле үткәрелгән дәресләрне гадәти булмаган дәресләр белән алмаштыру уку-укыту барышын кызыклы итеп кенә калмый, балага өйрәнелә торган материалны аңларга да булыша. Дәрестә ялыктыргыч эш төрләрен башкаруга караганда, кызыклы ачышлар булганы, укучының күңеленә тәэсир итә, аң-белемен киңәйтә һәм иҗади эзләнүгә теләк тудыра. Шуңа да соңгы вакытта укучының белем сыйфатын күтәрүдә, иҗади сәләтләрен үстерүдә яңа технологияләрне өйрәнү һәм дәрестә куллану турында күп сөйләнелә, языла.

Берничә заманча технология кулланып үткәрелә торган квест-дәрес өчен материал тәкъдим ителә.

**QR-квест**

1 этап – әзерлек.

Укытучы укучылар белгән лексиканы истә тотып, башваткыч төзи. Биремнәрне QR-кодларга әйләндерә. Моның өчен http://www.qrcoder.ru/ адресы белән кереп, QR-кодлар генераторын файдаланырга була.

Һәр кодта биремнән тыш, команда алга таба ничек хәрәкәт итәргә тиешлеге дә аңлатыла.

Укытучы QR-кодларны сыйныфның төрле җиренә урнаштыра. Квест узганда командалар бер-берсенә комачауламаска тиеш.

2 этап – квестны узу.

Сыйныф ике командага бүленә. Укытучы һәр командага буш башваткыч ясалган кәгазьне тапшыра һәм старт командасын бирә. Бер кодтан икенче кодка бара-бара, укучылар башваткычның буш урыннарын тутыралар.

3 этап – йомгаклау.

Биремнәрнең барысы да төгәл итеп эшләнеп беткәннән соң, укучылар “Хәрефләр” бланкына кара хәреф белән билгеләнгән хәрефләрне күчереп язалар һәм ул хәрефләрдән сүз төзиләр.

## Квест өчен биремнәр.

***Башваткыч***

Сүзләрнең тәрҗемәсен яз.

1. Дятел 2. Еж 3. Гриб 4. Дерево 5. Белка




***Командаларга бирелә торган буш башваткыч***

Сүзләрнең тәрҗемәсен яз.



*“Хәрефләр” бланкы беренче команда өчен*

| | | | | |
|---|---|---|---|---|

*“Хәрефләр” бланкы икенче команда өчен*

| | | | | |
|---|---|---|---|---|

**QR-кодлар**

**Беренче команда өчен**

| QR-код | *Текст* |
|---|---|
| Старт | QR-квестны башла. Беренче бирем тактада**.** |
| Такта | Дятел<br>Икенче бирем – укытучы янында. |

| | |
|---|---|
| Укытучы янында | Еж<br>Алдагы бирем – беренче партада |
| Беренче парта | Гриб<br>Алдагы биремне икенче партадан тап |
| Икенче парта | Дерево<br>Алдагы бирем – ишекне кара! |
| Ишек | Белка<br>Укытучы янына бар! |

### *Икенче команда өчен*

| QR-код | *Текст* |
| --- | --- |
| Старт | QR-квестны башла. Беренче бирем сул як стенада. |
| Сул як стена | Дятел<br>Икенче бирем – шкафта. |
| Шкаф | Еж<br>Икенче бирем – бишенче партада. |
| Бишенче парта | Гриб<br>Алдагы биремне алтынчы партадан кара. |

| | |
|---|---|
| Алтынчы парта | Дерево<br>Алдагы бирем – интерактив тактада. |
| Интерактив такта | Белка<br>Укытучы янына бар! |

# ӘДӘБИЯТ

*Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н.* Әдәбият дәресләрендә шәхескә бәйле универсаль уку гамәлләрен формалаштыру. Методик ярдәмлек. – Казан, 2018. 48 б.

*Гайнуллина Г.Ф., Гиниятуллина Л.М.* #ЭрудитТатарча / Г.Ф. Гайнуллина, Л.М. Гиниятуллина. – Казан: Республика олимпиада үзәге, 2017. – 70 б.

*Шәкүрова М.М.* Татар телен укыту методикасы: Теория һәм практика / М.М. Шәкүрова, А.Ф. Йосыпов. – Казан: Казан дәүләт ун–ты нәшр., 2009. – 168 б.

*Шәкүрова М.М.* Икетеллелек шартларында фигыль сүз төркемен татар, рус һәм алман телләрендә чагыштырып өйрәнү. Уеннар / М.М. Шәкүрова // Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: проблемы и перспективы: материалы международной научно-практической конференции (Казань, 19–21 октября 2017г.) / под ред. Р.Р. Замалетдинова. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2017. – С.371–374

*Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М.* 1–4 нче сыйныфларда «Туган тел» предметын яңача укыту. Методик ярдәмлек / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина. – Казан, 2018. – 36 б.

## Эчтәлек


КЕРЕШ СҮЗ.................................................................................................. 4

УЙНАВЫН УЙНА…........................................................................................ 5

Уеннарны оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләре

Телгә өйрәтү уеннарын классификацияләү................................................. 7

Җырдай моңлы татар теле.......................................................................... 10

*«Туган тел» дәресе өчен уеннар* ................................................................ 10

Әдәбият дөньясына сәяхәт

*«Әдәби уку» дәресе өчен уеннар* ................................................................ 27

Җаваплар...................................................................................................... 45

*Кушымта* ...................................................................................................... 52

ӘДӘБИЯТ ..................................................................................................... 58

Методическое пособие

**Шакурова** Муслима Магесумовна

**Гиниятуллина** Лилия Миннулловна

**Мухарлямова** Гульназ Нурфатовна

**Абдуллина** Дилярия Маратовна

# Дидактические игры

Для применения на уроках «Родного (татарского) языка»

И «Литературного чтения на родном языке»

(для начальных общеобразовательных организаций)

На татарском языке

---

Методик әсбап

**Шәкүрова** Мөслимә Мәгъсүм кызы

**Гыйниятуллина** Лилия Миңнулла кызы

**Мөхәрләмова** Гөлназ Нурфат кызы

**Абдуллина** Диләрия Марат кызы

# Дидактик уеннар

«Туган тел (татар теле)» һәм «Әдәби уку» дәресләрендә куллану өчен

(башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен)